**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ДӨРЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«01» ноябрь, 2025ел Иске Дөреш авылы № 12

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Таулы Дөреш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында «нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 31 октябрендәге 8/1 номерлы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Советы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2025 елның 14 ноябренә 13:00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Таулы Дөреш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елның 25 октябрендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча уздырылган гражданнар җыены йомгаклары буенча җыелган акчалар исәбенә ***«торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Таулы Дөреш авылының Ленин урамындагы юл чокырларын ремонтлау)***» эш төрен ***«торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (традицион күмү урынына бара торган юл өчен вак таш сатып алу)***» эш төренә үзгәртергә ризамы?»

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Таулы Дөреш авылы, Ленин урамы, 52.

4. РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү, контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, Иске Дөреш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә.

5. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

8. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Иске Дөреш авыл җирлеге Башлыгы Р.М. Дусадбеков